КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 декабрь г.Казань № 1103

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә «Ворлдскиллс» хәрәкәтен үстерү, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча әзерлек буенча эталон программаларын эшләү, сынау һәм гамәлгә ашыру өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмага субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 9 декабрь, 1304 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 18 апрель, 486 нчы карарындагы 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 декабрь, 1304 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә «Ворлдскиллс» хәрәкәтен үстерү, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча эталон әзерлек программаларын эшләү, сынау һәм гамәлгә ашыру өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2024 ел, 12 сентябрь, 767 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин